| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» август 2019г. г. Альметьевск № 168

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 28 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә хакында» 60 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2019 елның 1 апрелендәге «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 48-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 28 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә хакында» 60 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2017 елның 30 мартындагы 74 номерлы, 2017 елның 5 маендагы 78 номерлы, 2017 елның 31 маендагы 83 номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 91 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 114 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 135 номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 146 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарга кушымтаның 9 бүлегендәге 9.3 пункты 6 пунктчасында «Муниципаль хезмәткә керү, аны үтү һәм туктату тәртибе»н түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) хезмәт килешүенең (контракт) беренче тапкыр төзелү очракларыннан тыш, индивидуаль исәп-хисап счеты; ».

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Бочкарев Н.А.).

Шәһәр башлыгы урынбасары А.М. Токарев

Зак. № 3223